# Балалар бакчалары җитәкчеләре утырышы беркетмәсе №1.

**Үткәрү вакыты**: 03.09.2020.
**Үткәрү урыны:** Балалар иҗат үзәге.
**Катнашнашырга тиеш**: район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А., РМО җитәкчесе Аглямова М.В., балалар бакчалары мөдирләре, өлкән тәрбиячеләр.
**Катнашалар**: 42 бакча мөдире, 5 өлкән тәрбияче, РМО җитәкчесе Аглямова М.В., район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А.

**Тема:** "Үткән уку елына анализ. Яңа уку елына эшчәнлек планнарын билгеләү»

**Көн тәртибе**:

1. Пандемия чорына куелган таләпләр. Л.М. Хафизова чыгышы.
2. "Яшел ут 2020" конкурсына нәтиҗә ясау. Лена Музаятовна чыгышы.
3. Узган уку елына йомгак ясау. Район мәгариф бүлеге мәктәпкәчә белем бирү буенча методист Ахтямова А.А. чыгышы.
4. "Электрон балалар бакчасы" Лейла Фазыловна чыгышы.
5. "Балалар бакчасында цифрлы технологияләр куллану ". Гомуми үсеш бирүче 1 санлы балалар бакчасы мөдире Закирҗанова Л.Р. чыгышы.
6. Башлангыч мәктәп-балалар бакчасында инглиз телен өйрәнүне тормышка ашыруда цифрлы караш. Р.Файзрахманова чыгышы.
7. Уен тренинг

**Утырыш барышы:**

1 нче көн тәртибе буенча сүз Л.М. Хафизовага бирелде, ул районда коронавирус буенча ситуация торышы белән таныштырды.

1. Бу уку елында эшне пандемия чорында башлап җибәрдек, барыбызда югарыдан төшерелгән САНИТАРНО-ЭПИДЕМИОЛОГИЧЕСКИЕ ПРАВИЛА СП 3.1/2.4.3598-20 "САНИТАРНО-ЭПИДЕМИОЛОГИЧЕСКИЕ ТРЕБОВАНИЯ К УСТРОЙСТВУ, СОДЕРЖАНИЮ И ОРГАНИЗАЦИИ РАБОТЫ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫХ ОРГАНИЗАЦИЙ И ДРУГИХ ОБЪЕКТОВ СОЦИАЛЬНОЙ ИНФРАСТРУКТУРЫ ДЛЯ ДЕТЕЙ И МОЛОДЕЖИ В УСЛОВИЯХ РАСПРОСТРАНЕНИЯ НОВОЙ КОРОНАВИРУСНОЙ ИНФЕКЦИИ (COVID-19)" таләпләренә катгый таянып эш оештыру шарт. Бу документ хезмәткәрләр белән өйрәнелергә һәм үтәлергә тиеш.
2. Районга Грипкка каршы профилактика вакциналары кайтты. Һәр мәгариф системасында хезмәт күрсәтүче дә бу прививкаларны ясатырга тиеш. Озакламый балалар өчен дә кайтып җитә, ата-аналар белән аңлату эшләре алып бирү кирәк, курыкмасыннар, дөрес аңласыннар иде, вакциналарның зыяны юклыгын.
3. Бала килми торган очракта справкалы булу катгый тикшереләчәк.
4. Бала балалар бакчасына алынган чагында Манту прививкасы булу шарт яисә педиатр, фтизиатр тарафыннан бирелгән справкасы булсын.
5. флюорографиясез бер хезмәткәр дә булмый.
6. иртән һәр хезмәткәр, һәр бала фильтр үтеп кенә учреждениягә керә. Авыру билгеләре булган очракта, табибка җибәрелергә тиеш була.

Инструкцияләрне бозып авыру очрагы теркәлсә, закон тарафыннан җаваплылыкка тартылу караралган, шуңа күрә бер беребезнең сәламәтлеген саклап эш итик.

2 көн тәртибе буенча сүзне ЮХИДИ буенча белгеч Лена Музаятовна алды.
Сүз башында республикада һәм районда юл йөрү куркынычсызлыгы турында мәгълүмәт белән таныштырды. Соңрак февраль аенда узган "Яшел ут - 2020" конкурсына нәтиҗә ясады, район буенча җиңүче балалар бакчаларын, аеры номинациядә җиңүче тәрбиячеләрне котлады, истәлекле бүләкләр тапшырды.
"Игътибар , балалар" акциясе булып үтүен билгеләде, актив катнашкан балалар бакчаларына рәхмәтен белдерде.